

Саранск шәһәрендә егетләр һәм кызлар арасында теннис буенча Ботенроссия ярышлары узды. Аларда илнен 24 шәһәреннән һәм 20 субъектыннан 59 спортчы коч сынашты. Үткән атнада турнирны ябу тантанасы узды.       Анда Мордовия башлыгы Артём Здунов һәм Халыкара Олимпия комитеты әгъзасы, Россия Теннис федерациясе президенты Шамиль Тарпищев катнашты.

«Мордовиянен Ботенроссия дә-рәҗәсендәге теннис турнирларын уздыру мәйданчыгы булып торуы кvнелле. Бу безнен спортчыларны тартып тора, кемнен ин яхшы формада булуын ачыкларга ярдәм итә.

Спорт - ахырга кадәр корәшергә кирәк булган эш! Сезнен алда яна ярышлар кvп, һәр спортчыга vз жинvегезне телим», - дип морәҗәгать итте Артём Здунов катнашучыларга. Ул шулай ук Шамиль Тарпищев һәм анын Россиядәге хезмәттәшләре оештырган теннис мәктәбе аркасында безнен спортчылар доньяда ин кочлеләр булып кала, дип билгеләп vтте.

Шамиль Тарпищев Артём Здуновка республикада теннис vсешенә керткән олеше очен рәхмәт белдерде: «Мордовиягә, барлык тренерларга һәм ата-аналарга рәхмәт. Теннис артында - киләчәк, бvгенге кондә булган традицияләрне сакларга һәм арттырырга кирәк».

Россия Теннис федерациясе президенты яшь спортчыларга унышлар һәм югары казанышлар теләде: «Бvген безнен ил- теннис доньясында лидер: 2021 ел нәтижәләре буенча Россия теннисчылары момкин булганнын барысын да оттылар!»

Артём Здунов һәм Шамиль Тарпищев турнир жинvчеләренә һәм призерларына бvләкләр тапшырдылар. Кызлар арасында оченче урынны Дарья Садыкова яулады, икенче- Софья Ведерникова, беренче – Милана Сафиуллина. Кирилл Филаретов егетләр арасында бронза призеры булды, Марк Кременский – комеш, Семен Конышев алтын медаль яулады.

Парлы разрядта Артём Ковалев һәм Дмитрий Ряпухин – егетләр арасында оченче, Роман Кожевников һәм Родион Малмыгин - икенче урын нарны яулыйлар, Семен Конышев һәм Леонид Руднев – жинvчеләр иделәр. София Климанова һәм Виктория Седенкова дуэты – кызлар арасында оченче, Софья Ведерникова һәм Милана Сафиуллина дуэты икенче урын яулыйлар, Дарина һәм Дарья Садыковалар парлы разрядта лидер булдылар.